| СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ РОМОДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 08.10.2019 | № 96 |

с.Ромодан

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге территорисендә гражданнарның үзара салымы һәмгражданнарның үзара салым акчаларыннан файдаланутурындагы нигезләмәсен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә

**Кыркүл авыл җирлеге карар итте:**

1.Бирелгән Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану турындагы нигезләмәне расларга.

22.Әлеге карарны Ромодан авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Ромодан авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **И.А. Чекалина**

ТатарстанРеспубликасыАлексеевск
муниципаль районы
Ромодан авыл җирлеге советының ел
№лы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге территорисендәгражданнарның үзара салымы һәмгражданнарның үзара салым акчаларыннан файдалану турындагы нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге территориясендә,гражданнарның үзара салымы тәртибендә,җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен ,халыкның өстәмә акчаларын җәлеп итү һәм алардан файдалану тәртибен җайга сала.

2.1. Гражданнар-җирлек чикләрендә даими яшәү урыны булган Россия Федерациясе гражданнары.

Үзара салым акчалары дигәндә, гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен башкарыла торган бер такыр түләүләре .

Гражданнарның үзара салымы җирле референдумда кабул ителгән карар буенча ,җирлек территориясендә кертелә.

Җирлек составына керүче торак пунктта гражданнар җыенында конкрет торак пункт территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре хәл ителә.

Гражданнарның үзара салымы күләме, җирлектә (торак пунктта) яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 процентган артмаган һәм түләү күләме киметелергә мөмкин булган аерым категорияләрдән тыш, барлык җирлек (торак пунктта) халкы өчен дә абсолют күләмдә тигез билгеләнә.

2. Үзара салым мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү

2.1.Үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә. Референдум үзара салым буенча түләүләр күләмнәрен һәм җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне раслый.

2.1. Гражданнарның үзара салым мәсьәләсе буенча җирле референдумын үткәрү инициативасы белән чыгу хокукына түбәндәгеләр ия:

-референдумда катнашу хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары;

- уставы сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда катнашуны күздә тоткан һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлгән сайлау берләшмәсенә, башка иҗтимагый берләшмәгә;

-Җирлек советына һәм Башкарма комитет җитәкчесенә,бергәләп тәгьдим иткәндә.

2.3. Җирле референдумны билгеләү турындагы карар җирлек Советы тарафыннан җирлек Советына җирле референдум билгеләнә торган документлар кергән көннән алып 30 көн эчендә кабул ителә.

2.4.Җирле референдумны әзерләү һәм үткәрү тәртибе «Җирле референдум турында»2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына.

2.5. Җирле референдумны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслау җирлек бюджеты хисабына башкарыла.

2.6.Тавыш бирү нәтиҗәләре һәм җирле референдумда кабул ителгән карар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан ителергә тиеш. Җирле референдумда кабул ителгән карар хокукый порталда урнаштыру юлы белән рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

2.7.Үзара салым билгеләү турында референдум карарын үтәү җирлекнең барлык гражданнары өчен мәҗбүри.

## 3. Үзара салым мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыру

3.1. Гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе Ромодан авыл җирлеге Уставы һәм җирлек Советы тарафыннан расланган «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында» Нигезләмә белән җайга салына.

## 4. Үзара салым акчаларын җыю тәртибе

4.1.Үзара салым акчаларын җыю тәртибе авыл җирлегенең хокукый акты белән җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән карарны тормышка ашыруга юнәлдерелгән, гражданнарның үзара салым акчаларын түләү бурычы билгеләнә торган срокларны билгели.

4.2. Әлеге акт вәкаләтле органнар тарафыннан «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның, «Җирле референдум турында»2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 60 статьясында каралган тәртиптә һәм срокларда чыгарыла.

## 5. Үзара салым чараларын куллану

5.1. Үзара салым буенча җыелган һәм җирлек бюджетына кергән акча җирле референдумда кабул ителгән карарда каралган җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне (конкрет мәсьәләне) хәл итүгә җирлек башкарма комитеты тарафыннан тотыла.

5.2. Хисап елында файдаланылмаган акчалар киләсе финанс елына күчә һәм референдум карарында каралган максатларга тотыла.

5.3. Җирлек башлыгы халык алдында җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлеше турында елга бер тапкыр хисап тота.

5.4.Җирлек башлыгының 5.3 пункты нигезендә әзерләнгән хисаплары. әлеге Нигезләмә нигезендә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителә.

5.5. Авыл җирлеге башкарма комитеты гражданнарның үзара салым түләүләренең , тулы һәм үз вакытында башкарылуын контрольдә тота.

6. Әлеге Нигезләмәне бозган өчен җаваплылык

6.1. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

6.2. Акчаларның максатчан кулланылышын тикшереп тору Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Ромодан авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** И.А. Чекалина